| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 2018 ел, 21 декабрь | г.Казань | № 1207 |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 ел, 21 ноябрь, 885 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 ел, 21 ноябрь, 885 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 декабрь, 932 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

«а» пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт милке» сүзләреннән соң «,шул исәптән инвестицияләрне нигезләү һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрү максатларында,» сүзләрен өстәргә, «(алга таба – оешмалар)» сүзләрен «шул исәптән казна (алга таба – оешмалар)» сүзләренә алмаштырырга»;

«б» пунктчасын «Татарстан Республикасы дәүләт милке» сүзләреннән соң «,шул исәптән инвестицияләрне нигезләү һәм анык технологик һәм бәя аудитын үткәрү максатларында,» сүзләрен өстәргә»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бюджет инвестицияләре һәм субсидияләр бирү Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $20^{1}$ статьясындагы 2 һәм $3^{1}$ пунктлары һәм $20^{1-2}$ статьясындагы 2 һәм $3^{1}$ пунктларында каралган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары (алга таба – карарлар) нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3 пунктта :

«а» пунктчасында «$20^{1}$ статьяның 2 пункты белән» сүзләрен «$20^{1}$ статьяның 2 һәм $3^{1}$ пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «$20^{1-2}$ статьяның 2 пункты белән» сүзләрен «$20^{1-2}$ статьяның 2 һәм $3^{1}$ пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

$3^{1}$ пунктта:

«а» пунктчасында «$20^{1}$ статьяның 2 пункты белән» сүзләрен «$20^{1}$ статьяның 2 һәм $3^{1}$ пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «$20^{1-2}$ статьяның 2 пункты белән» сүзләрен «$20^{1-2}$ статьяның 2 һәм $3^{1}$ пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $4^{1}$ пункт өстәргә:

«$4^{1}$. Россия Федерациясе законнары нигезендә капиталь төзелеш объекты өчен инвестицияләрне нигезләү әзерләү мәҗбүри булган очракта бюджет инвестицияләре һәм инвестицияләрне нигезләү һәм анык технологик һәм бәя аудиты үткәрү максатларында субсидияләр бирү гамәлгә ашырыла.»;

5 пунктта «оператив идарә хокукында булган» сүзләреннән соң «яки хуҗалык алып бару» сүзләрен өстәргә, «яисә арттыру» сүзләрен «шулай ук арттыру» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктка «оператив идарә» сүзләреннән соң «яки хуҗалык алып бару» сүзләрен, «җәлеп итә» сүзләреннән соң «шулай ук» сүзләрен өстәргә;

7 һәм 8 пунктларда «төзелеш максатларында төзелгән» сүзләрен «проект һәм (яки) эзләнү эшләрен башкару, төзелеш максатларында төзелгән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $10^{1}$ һәм $10^{2}$ пункт өстәргә:

«$10^{1}$. Әлеге Кагыйдәләрнең 10 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр объектларга бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда, алга таба аларны мондый юридик затларның устав (склад) капиталларына кертем сыйфатында тапшыру белән,вәкаләтләрне бирү турындагы килешүләр нигезендә һәм карарлар белән акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган юридик затларга бирелергә мөмкин.

$10^{2}$. Объектларны әлеге Кагыйдәләрнең $10^{1}$ пунктында күрсәтелгән юридик затларның устав (склад) капиталларына кертем сыйфатында тапшыру күрсәтелгән юридик затларның устав (склад) капиталларының эквивалент өлешенә Татарстан Республикасы дәүләт милке хокукы барлыкка килүгә китерә, ул Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә мондый юридик затларның устав (склад) капиталларында Татарстан Республикасы катнашуы белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы устав (склад) капиталында Татарстан Республикасы өлешен рәсмиләштерү Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган тәртиптә һәм бәяләр буенча гамәлгә ашырыла.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«11. Вәкаләтләрне тапшыру турында килешү берничә объектка карата төзелергә мөмкин. Вәкаләтләрне тапшыру турында килешү һәм әлеге килешүгә өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган формалар нигезендә төзелә.»;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ һәм $11^2$ пунктлар өстәргә:

«$11^1$. Инвестицияләрне нигезләү һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрү максатларында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда тапшырыла торган вәкаләтләрдән тыш, вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүдә шул исәптән түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру максаты һәм аларның күләме, һәр объектка карата, аның исемен, егәрлеген, төзелеш (үзгәртеп коруның, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник яктан яңадан коралландыру) яисә Татарстан Республикасы дәүләт милкенең капиталь төзелеш объектының тиешле ел бәяләре (смета яки фаразлана торган (чик) яисә Татарстан Республикасы дәүләт милкенә күчемсез мөлкәт объекты сатып алу бәясен күрсәтеп, ел саен бүлү белән) тиешле карарларга туры килә торган объект сатып алу, шулай ук тиешле ел бәяләре белән исәпләнгән капиталь кертемнәрнең гомуми күләме, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына (дәүләт органына) каралган бюджет ассигнованиеләре күләме күрсәтелгән;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы) йөзендә Татарстан Республикасы исеменнән дәүләт контрактларын төзү һәм үтәү буенча оешманың хокукларын һәм бурычларын билгели торган нигезләмәләр;

в) тапшырылган вәкаләтләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен оешманың җаваплылыгы;

г) оешмалар тарафыннан төзелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү белән билгеләнгән шартлар үтәлешен тикшерүне үткәрүгә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының (дәүләт органы) хокукын билгели торган нигезләмәләр;

д) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына (дәүләт органына) бюджет хисабын алып бару, бюджет хисабын төзү һәм тапшыру буенча оешманың бурычын билгели торган нигезләмәләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә.

$11^2$. Инвестицияләрне нигезләү һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрүне әзерләү максатларында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда тапшырыла торган вәкаләтләрне тапшыру турында килешү үз эченә шулай ук әлеге Кагыйдәләрнең $11^1$ пунктындагы «б» – «д» пунктчаларында каралган нигезләмәләрне дә алырга тиеш, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына (дәүләт органына) каралган бюджет ассигнованиеләре күләмен, инвестицияләр

нигезләүне әзерләү һәм аның технологик һәм бәя аудиты үткәрү максатларында, бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру максаты – һәр объектка карата аның исемен, инвестицияләрне нигезләү вакытын һәм технологик һәм бәя аудиты үткәрү вакытын һәм капитал салуларның гомуми күләмен күрсәтеп, тиешле карар кабул ителде.»;

14 пунктта «бюджет акчалары» сүзләрен «бюджет ассигнованиеләре» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәргә:

«$15^1$. Дәүләт заказчысы вәкаләтләрен әлеге Кагыйдәләрнең $10^1$ пунктында күрсәтелгән юридик затларга тапшырганда, аларга оешмалар өчен әлеге Кагыйдәләрнең 11 – 13 пунктлары белән билгеләнгән нигезләмәләр кагыла. Әлеге Кагыйдәләрнең 11 пунктында каралган шартларга өстәп, Татарстан Республикасы милкендә булган юридик затка вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүдә бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән объектларны күрсәтелгән юридик затның устав (склад) капиталына кертем сыйфатында тапшыру тәртибен һәм срокларын билгели торган нигезләмәләр булырга тиеш.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидия бирү турындагы килешү берничә объектка карата төзелергә мөмкин. Субсидияләр бирү турында килешү һәм әлеге килешүгә үзгәрешләр кертүне яисә аны үстерүне күздә тота торган өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган формалар нигезендә төзелә.»;

түбәндәге эчтәлекле $16^1$ һәм $16^2$ $15^1$ пунктлар өстәргә:

«$16^1$. Субсидияләр бирү турындагы килешү, инвестицияләрне нигезләү һәм технологик һәм бәя аудиты үткәрү максатларында бирелгән субсидияләрдән тыш, түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) субсидия бирү максаты һәм аның еллар буенча бүлеп күләме һәр объектка карата, аның исемен, егәрлеген, төзелеш вакытын (үзгәртеп кору, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник яктан яңадан коралландыру) яисә карарга туры килгән тиешле ел бәяләре белән исәпләнгән объектны сатып алу турында (Татарстан Республикасы дәүләт милкенең капиталь төзелеш объектының яисә күчемсез мөлкәт объектын дәүләт милкенә сатып алу бәясенең сметалы яисә фаразланыла торган (чик) бәясеннән чыгып), шулай ук финанслар белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбенә капитал салуларның гомуми күләмен, шул исәптән тиешле карарда бирелә торган субсидия күләмен күрсәтеп;

б) субсидияләр бирү турында килешү якларның хокукларын һәм бурычларын һәм субсидияләр бирү турында килешүне гамәлгә ашырганда аларның үзара эшчәнлек тәртибен билгели торган нигезләмәләр;

в) субсидияләрдән файдаланганда оешма тарафыннан дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән нигезләмәләрне үтәү турында шарт;

г) субсидияләр белән операцияләрне исәпкә алу өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында шәхси счет ачу буенча Татарстан Республикасы дәүләт

автоном учреждениесе һәм Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе вазыйфаларын, шул исәптән казна вазыйфаларын билгели торган нигезләмәләр;

д) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең, шул исәптән казна предприятиесенең субсидия кулланмыйча гына капиталь төзелеш объектларына проект документларын эшләүне һәм мондый проект документларын әзерләү өчен башкарыла торган инженерлык эзләнүләрен үткәрүне гамәлгә ашырырга, капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементлары, техник яктан яңадан җиһазландыру) буенча инвестиция проектларына технологик һәм бәя аудиты үткәрү, проект документларына аудит үткәрү, проект документларына һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә, капиталь төзелеш объектларының смета бәясен дөрес итеп билгеләүне тикшерү үткәрү, субсидия бирү каралган төзелешне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрация элементлары белән дә) финанс белән тәэмин итүгә дәүләт экспертизасы үткәрү;

е) әгәр бу максатларга субсидияләр бирү карар белән каралмаган булса, Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең яисә Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесенең әлеге пунктның «д» пунктчасында күрсәтелгән чараларны үткәрүгә бәйле чыгымнарны субсидияләр бирмичә генә гамәлгә ашыру йөкләмәсе;

ж) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең, шул исәптән казна предприятиесенең объектны эксплуатацияләүгә (сатып алуга) керткәннән соң объектны карап тоту өчен кирәкле эксплуатация чыгымнарын, әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын кулланмыйча гамәлгә ашыру йөкләмәсе;

з) Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең яисә Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесенең эксплуатацияләүгә (сатып алуга) кертелгәннән соң объектны карап тоту өчен кирәкле эксплуатация чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр исәпләгәндә кулланыла торган тиешле норматив чыгымнар күләменнән артмаган күләмдә үтәүне (эшләр башкаруны) гамәлгә ашыру йөкләмәсе;

и) субсидияләрне күчерү сроклары (срокларын билгеләү тәртибе), шулай ук субсидияләр белән операцияләрне исәпкә алу өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетка субсидияләрне күчерү бурычын билгели торган нигезләмәләр;

к) субсидия бирә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучының субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән шартларны үтәүне тикшерүне үткәрүгә хокукын билгели торган нигезләмә;

л) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучының әлеге Кагыйдәләрнең 22 пунктында күрсәтелгән капиталь кертүләргә субсидияләр бирү максатларына әлеге акчаларны җибәрү ихтыяҗы булу турында субсидия бирә торган карары булмаган очракта, оешма тарафыннан алдагы финанс елы башына моңарчы күчерелгән субсидияне чираттагы финанс елы башына файдаланылмаган калдык күләмендә акчаны кире кайтару тәртибе;

м) тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән максат һәм шартларны бозу фактлары ачыкланган очракта оешма тарафыннан кулланылган суммаларны кире кайтару тәртибе;

н) карар белән мондый шарт каралган очракта финанслауның башка чыганаклары хисабына объектларга капитал салуларны финанслау шартларын оешма тарафыннан бозу белән бәйле субсидияләр бирүне туктатып торуны яисә бирелә торган субсидия күләмен киметүне күздә тота торган нигезләмәләр;

о) субсидияләрдән файдалану турында оешма тарафыннан хисап бирү тәртибе һәм вакытлары;

п) субсидия бирү турындагы килешүгә үзгәрешләр кертү очраклары һәм тәртибе, шул исәптән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучыга моңа кадәр билгеләнгән тәртиптә субсидия бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта да, шулай ук субсидия бирү турындагы килешүне вакытыннан алда туктату очраклары һәм тәртибе.

$16^2$. Инвестицияләрне нигезләү һәм технологик һәм бәя аудиты үткәрү максатларында субсидияләр бирү турындагы килешү шул исәптән әлеге Кагыйдәләрнең $16^1$ пунктындагы «б» – «г» һәм «и» – «п» пунктчаларында каралган нигезләмәләр, шулай ук субсидия бирү максаты һәм аның күләме, инвестицияләрне нигезләүне әзерләүгә һәм аның технологик һәм бәя аудиты үткәрүгә капитал салуларның гомуми күләмен, шул исәптән бирелә торган субсидия күләме булырга тиеш, тиешле карарда, инвестицияләрне нигезләү срокларын һәм технологик һәм бәя аудитын үткәрү срокларын күрсәтеп, һәр объектка карата ел саен бүлү белән.»;

19 пунктка «кергән оешмаларга» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла һәм» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы икенче – ундүртенче, унҗиденче, унсигезенче, егерме икенче – утыз беренче, утыз бишенче – илле дүртенче абзацлары 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин